**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422622 с.Сокуры,
ул. Школьная, д.1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

2024 елның «18» октябре 50 номер

**К А Р А Р**

**Физик затлар мөлкәтенә салым турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салымны мәҗбүри түләүгә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

- гаражлар һәм машина урыннарына карата;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларына яисә корылмаларга карата;

- мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гараж яисә машина урыны. Ставка салым түләүче сайлаган бер гаражга яисә машина урынына карата билгеләнә,;

2) 0,2 процент:

квартиралар, квартираларның өлешләре, бүлмәләргә карата;

3) 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләренә карарта;

- төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплексларга карата;

4) Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент;

5) 2025-2027 елларда 1,2 процент, 2028 елда 2,0 процент һәм алга таба:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;
- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары.

6) Башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

3. Түбәндәге салым ташламаларын билгеләргә:

3.1. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукына ия физик затларга исәпләнгән салым суммасын шушы фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

В случае, если квартира находится в общей совместной собственности, сумма льготы исчисляется для каждого из участников совместной собственности в равных долях.

Бу чакта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аны исәпкә алмыйча гына арта алмый.

3.2. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга (ата-аналарга, уллыкка алучыларга, опекуннарга, попечительләргә), шулай ук күрсәтелгән затларның 18 яшькә кадәрге балаларына физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән тулысынча азат итү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата ташлама бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2)торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

3)гараж яисә машина урыны.

Салым ташламалары салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүче сайлавы буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан, салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз сайлавы буенча салым ташламалары бирү турындагы гаризаны тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар бирергә хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган үз сайлган объектлар турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына салым чорыннан башлап шушы объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

5. Әлеге карар үз көченә кергән көннән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2014 елның 14 ноябрендәге 106 номерлы карары(25.05.2015 № 130, 16.10.2015 № 08, 18.10.2018 № 31, 02.11.2018 № 35/1, 17.12.2018 № 45, 09.10.2020 № 11, 28.11.2022 № 55, 27.05.2024 № 24 карарлары үзгәрешләре белән)үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Сокуры**
**авыл җирлеге Советы рәисе Р.Н. Газизуллин**